**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ**

**«26» сентябрь, 2017 ел №68**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Малосалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы нигезендә карар чыгарды :

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

12 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) аны чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип тану, шул законлы нигезләрдә булмаса (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан гайре) - күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү өчен Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясенә билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 10 ел эчендә, ә күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясенең күрсәтелгән бәяләмә буенча карарына карата судка шикаять белдерелгән булса, - суд карары законлы көченә кергән көннән алып 10 ел дәвамында гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә карата хокуклары бозылмаган дип танылган.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9, Мәдәният йорты бинасы;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9, авыл китапханәсе Мәдәният йорты бинасына керергә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлек советы рәисе А.Г.Җиһаншин**